**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2006 елның 23 октябрендәге ПУ-431 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 29 гыйнварындагы ПУ-61 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «,шулай ук кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «һәм кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктта «Департамент тарафыннан» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның икенче абзацында «атасының исеме» дигән сүзләрдән соң «(булган очракта)» дигән сүзләр өстәргә;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры һәм Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрлары, аларга кертелгән үзгәрешләр, алардагы мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, чикләүдән, күчермә алудан, бирүдән, таратудан, шулай ук башка төрле законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итеп, Мәгълүмат системасында саклана.»;

22 һәм 23 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ үз көченә кергәнче кәгазьдә тутырылган Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры алардан рөхсәтсез файдаланырга мөмкинлек бирми торган режимда алар тутырылган көннән алып 5 ел дәвамында (алар буенча хисап бирү катгый таләп ителгән документлар буларак) саклана, шуннан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә саклау өчен архивка тапшырыла».

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларыннан һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрыннан мәгълүматларны ел саен 1 гыйнварга булган торышында резерв күчермә алуны, Россия Федерациясе законнарында шәхси мәгълүматларны саклауга куелган таләпләр нигезендә аларны саклауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 12 февраль
№ ПУ-132